**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 22.02.2023** **№ 304**

# «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ нә ведомство буйсынуындагы мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы оешмалары җитәкчеләре вазыйфаларына кандидатларны һәм җитәкчеләрен аттестацияләү тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 51 статьясының 4 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы оешмалары җитәкчеләрен (директорларын, мөдирләрен) һәм җитәкчеләре (директорлары, мөдирләре) вазыйфасына кандидатларны аттестацияләгәндә бертөрлелекне тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Җитәкчеләр вазыйфаларына кандидатларны аттестацияләү тәртибе турында рекомендацияләр җибәрү турында» 2020 елның 31 декабрендәге 1523720 номерлы хаты нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кушымтада бирелгән «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ нә ведомство буйсынуындагы мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы оешмалары җитәкчеләре вазыйфаларына кандидатларны һәм җитәкчеләрен аттестацияләү тәртибен расларга (алга таба - тәртип) (1 нче кушымта).
2. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ буйсынуындагы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы оешмалары җитәкчеләре (директорлары, мөдирләре) вазыйфасына кандидатларга һәм җитәкчеләренә (директорларына, мөдирләренә) аттестация үткәрү вәкаләтләрен «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ нә йөкләргә
3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмалары җитәкчеләрен (директорларын, мөдирләрен) аттестацияләү тәртибе турында нигезләмәне раслау турында» 2016 елның 07 июлендәге 1220 номерлы карарын (29.05.2017 № 1399, 26.03.2018 № 675 редакциясендә) үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары - мәгариф бүлеге башлыгы Н.К. Әхмәтҗановка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин

Расланды»
Биектау муниципаль районы
Башкарма комитетының
2023 елның 22 феврале 304 нче
номерлы карарына 1 кушымта

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ нә ведомство буйсынуындагы мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы оешмалары җитәкчеләре (директорлары, мөдирләре) вазыйфаларына кандидатларны һәм җитәкчеләрен (директорлары, мөдирләре) аттестацияләү тәртибе

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Биектау муниципаль районы белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалары җитәкчеләре (директорлар, мөдирләр) вазыйфаларына кандидатларны һәм җитәкчеләрен (директорлары, мөдирләре) аттестацияләүнең әлеге тәртибе (алга таба - тәртип) «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ нә ведомство буйсынуындагы Биектау муниципаль районы белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмалары җитәкчеләр (директорлар, мөдирләр) вазыйфаларына кандидатларга (алга таба кандидат) һәм җитәкчеләренә (директорлары, мөдирләре) (алга таба - җитәкчеләр) аттестация үткәрү тәртибен «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 51 статьясының 4 өлеше нигезендә регламентлый.

1.2. Җитәкчеләр вазыйфаларына кандидатларны һәм җитәкчеләрне аттестацияләү тәртибе Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты карары белән билгеләнә.

1.3. Аттестация этапларын узу процедурасы Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2010 елның 26 августындагы 761н боерыгы белән расланган (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы тарафыннан 2010 елның 6 октябрендә теркәлгән, теркәү № 18638), Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2011 елның 31 маендагы 448н номерлы боерыгы белщнкертелгән үзгәрешләр белән (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы тарафыннан 2011 елның 1 июлендә теркәлгән, теркәү № 21240), «Мәгариф хезмәткәрләре вазыйфаларына квалификация характеристикалары» бүлегендә җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазыйфаларының Бердәм квалификация белешмәлегендә күрсәтелгән квалификация таләпләре нигезендә эшләнгән.

1.4. Кандидатларны аттестацияләү белем бирү оешмасы җитәкчесе вазыйфасына куела торган белемнәрне һәм квалификацияне бәяләү максатларында уздырыла.

1.5. Аттестациянең төп принцибы булып аны мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмага җитәкчеләр һәм җитәкче вазыйфасына дәгъва кылучы затлар өчен үткәрүнең мәҗбүрилеге тора.

1.6. Җитәкчеләрне һәм җитәкче вазыйфасына дәгъва кылучы затларны аттестацияләү, кагыйдә буларак, алар белән хезмәт килешүе төзегәнчегә кадәр, башка очракларда - хезмәткәр өчен хезмәт шартнамәсе шартлары белән билгеләнгән сынау срогы тәмамланганчыга кадәр уздырыла.

1.7. Җитәкчеләрне аттестацияләү биләгән вазыйфага карата куела торган белем һәм квалификацияне бәяләүне раслау максатларында уздырыла.

1.8. Аттестация комиссиясенең аларга карата уңай карары кабул ителгән җитәкчеләр һәр 5 ел саен кабат аттестация узалар.

1.9. Җитәкченең квалификация таләпләренә туры килүе турында аттестация комиссиясе карары түбәндәге очракларда саклана:

- җитәкченең башка белем бирү учреждениесенә эшкә күчүе;

- эштән туктап торганнан соң җитәкче вазыйфасында эшне яңадан башлау (декрет ялы, 1 ел һәм аннан да күбрәк вакытка административ отпуск, контрактны кабат рәсмиләштерү)

2. Аттестация узу

2.1. Кандидатларны һәм җитәкчеләрне аттестацияләү «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ төзелгән аттестация комиссиясендә уздырыла. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф бүлеге» МКУ җитәкчесе һәр аттестация үтүче хезмәткәр буенча карарлар кабул иткәндә комиссиясе тарафыннан закон белән һәм белем бирү оешмалары җитәкчеләре вазыйфалары буенча квалификация характеристикалары билгеләнгән таләпләрне үтәү өчен үтәү өчен җаваплы.

2.2. Аттестация түбәндәге эзлекле этапларны үз эченә ала:

а) башлангыч этап - тәкъдим ителә торган гаризаны анализлау;

б) тестлаштыру - белем дәрәҗәсен бәяләү процедурасын үтү, аттестацияләү турында күзаллауны тутыру.

2.3. Алдагы аттестация срогы тәмамланырга 6 айдан да соңга калмыйча, аттестация үтүче аттестация комиссиясенә аңа аттестация үткәрү турында, вазыйфасы буенча квалификация характеристикасында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау максатында, язма гариза бирә (1 нче кушымта). Җитәкче вазыйфасына дәгъва кылучы затлар гаризага хезмәт кенәгәсеннән таныкланган өземтәне теркәп куялар.

2.4. Аттестация барышында кандидатлар һәм җитәкчеләр аттестация комиссиясе вәкиле катнашында җитәкче вазыйфасы буенча аларның хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча тест рәвешендә квалификация сынаулары уза. Тест үткәрү сроклары һәм тестлар мәгариф бүлеге боерыгы белән раслана.

Тест нәтиҗәләрен уңай исәпкә алу өчен кирәкле балларның минималь күләме 50 баллдан 30 балл тәшкил итә.

2.5. Тест нәтиҗәләре турында документны аттестация комиссиясенә бирү буенча гамәлгә куючыны тәкъдим итүче «Татарстан Республикасы Биектау

муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы имзасы белән аттестация комиссиясенә күрсәтмә рәсмиләштерелә (2 нче кушымта).

2.6. Күрсәтмә әзерләгәндә, аттестацияләнүче хезмәткәрдән эш урыныннан тәкъдимнәр, характеристикалар, аның хезмәт эшчәнлеген характерлаучы башка документлар таләп ителергә мөмкин.

Аттестацияләнүче күрсәтмә белән үткәрү вакыты гамәлгә куючының акты белән расланган график белән билгеләнгән аттестациягә кадәр ике атнадан да соңга калмыйча таныштырылырга тиеш.

2.7. Аттестацияләнүче хезмәткәрнең гаризасы һәм тәкъдим аттестация комиссиясендә карала.

2.8. Аттестацияләнүче хезмәткәр аттестация вакытында аттестация комиссиясе утырышында шәхсән үзе катнашырга хокуклы, бу хакта аттестация комиссиясенә язмача хәбәр итә. Аттестацияләнүче хезмәткәр җитди сәбәпсез аттестация комиссиясесенә килмәгән очракта, комиссия аттестацияне аннан башка уздырырга хокуклы.

2.9. Аттестацияләнүче хезмәткәр булмаганда, аттестация комиссиясе карары аттестация комиссиясе утырышында катнашучыларның күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Аттестация комиссиясе әгъзаларының тавышлары тигез санда булганда, хезмәткәр аттестация узган дип санала.

2.10. Аттестация комиссиясе утырышында турыдан-туры катнашучы хезмәткәрне аттестацияләү нәтиҗәләре аңа тавыш бирү йомгакларын ясаганнан соң хәбәр ителә.

2.11. Җитәкчене аттестацияләү нәтиҗәләре буенча аттестация комиссиясе түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

- квалификация характеристикасында билгеләнгән таләпләргә туры килә (вазыйфасы күрсәтелә);

- һөнәри әзерлек яисә квалификация күтәрүне (белгечлек күрсәтелә) уңышлы узган очракта квалификация характеристикасында билгеләнгән таләпләргә (вазыйфасы күрсәтелә) туры килә;

- квалификация характеристикасында билгеләнгән таләпләргә туры килми (вазыйфасы күрсәтелә).

2.12. Аттестация комиссиясе карары тавыш бирүдә катнашучы комиссия рәисе, рәис урынбасары тарафыннан имзаланган көннән үз көченә керә торган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Кирәк очракта, аттестация комиссиясе, аттестация комиссиясе карарына хезмәткәрнең, белгечлеген күрсәтеп, һөнәри эшчәнлеген камилләштерү, аның квалификациясен күтәрү зарурлыгы турында һәм башка тәкъдимнәр кертә..

Күрсәтелгән тәкъдимнәр булган очракта, җитәкче аттестация уздырганнан соң бер елдан да соңга калмыйча аттестация комиссиясенә рекомендацияләр үтәү турында мәгълүмат тапшыра.

Аттестация нәтиҗәләре турында аттестация комиссиясе карары «ТР Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУның боерык акты белән раслана.

Боерык актының күчермәсе җитәкченең шәхси эшендә саклана.

3. Аттестация комиссиясенең функцияләре, вәкаләтләре, составы һәм эш тәртибе

3.1. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ аттестация үткәрү өчен:

а) аттестация комиссиясе төзи;

б) аттестация комиссиясе эше өчен документлар әзерли;

в) аттестация комиссиясе эшчәнлеген тәэмин итү максатларында башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

3.2. Аттестация комиссиясе иҗтимагый башлангычларда эшли.

3.3. Аттестация комиссиясе эшчәнлегенең төп принциплары булып компетентлык, объективлык, хәбәрдарлык, бәйсезлек, һөнәри этика нормаларын үтәү тора.

3.4. Аттестация комиссиясе түбәндәгеләргә хокуклы: а) соратып алына торган документларны, материалларны һәм мәгълүматны тапшыру срокларын билгеләргә;

б) кирәкле консультацияләр үткәрергә;

в) составын аттестация комиссиясе раслый торган экспертлар һәм белгечләр җәлеп итеп эшче төркемнәр төзү.

3.5. Аттестация комиссиясе составы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ боерыгы белән раслана.

Аттестация комиссиясе составына (килешү буенча керүне дә кертеп) Татарстан Республикасы Биектау МР мәгариф бүлеге вәкилләре, мәгариф хезмәткәрләренең һөнәр берлеге рәисе керә.

3.6. Аттестация комиссиясе эшчәнлегенә гомуми җитәкчелекне аттестация комиссиясе рәисе гамәлгә ашыра, ул аттестация комиссиясе эшен оештыра, аның утырышларында рәислек итә, кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыруга гомуми контрольне гамәлгә ашыра, аттестация комиссиясе әгъзалары арасында вазыйфаларны билгели. Аттестация комиссиясе рәисе булмаган очракта, аттестация комиссиясе рәисе функцияләрен тулы күләмдә аттестация комиссиясе рәисе урынбасары башкара. Аттестация комиссиясенең җаваплы секретаре аттестация комиссиясе карарлары материалларын һәм проектларын әзерли, аттестация комиссиясе исеменнән соратулар һәм хәбәрнамәләр җибәрә, аттестация комиссиясе карарларын аттестацияләнүчеләргә, Татарстан Республикасы Биектау МР белем бирү оешмалары җитәкчеләренә җибәрелүен тәэмин итә.

3.7. Аттестация комиссиясе үз эшен оештыру тәртибен мөстәкыйль билгели.

3.8. Аттестация комиссиясе карарлары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә, аларга аттестация комиссиясе әгъзалары имза сала. Аттестация комиссиясенең кабул ителгән карар белән килешмәгән әгъзасы, үзенең аерым фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы, ул аттестация комиссиясе утырышы беркетмәсенә кушымта итеп бирелә.

3.9. Аттестация комиссиясенең аттестацияләнүчеләргә карата кабул ителгән карарлары беркетмәдән өземтә рәвешендә аттестация комиссиясе утырышыннан соң өч эш көне эчендә рәсмиләштерелә һәм аттестацияләнүчегә җибәрелә.

4. Аттестация уздыруны методик һәм оештыру-техник тәэмин итү

4.1. Аттестация уздыруны һәм аттестация комиссиясе эшчәнлеген методик һәм оештыру-техник тәэмин итүне «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ гамәлгә ашыра.

4.2. Тест этабы кәгазь рәвештә уздырыла.

4.3. Аттестацияләнүчеләрнең карарларына тикшерүне «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУның аттестация комиссиясе вәкилләре гамәлгә ашыра. Белем бирү оешмасы җитәкчесе вазыйфасына бер аттестацияләнүчегә карата аттестация комиссиясе вәкилләренең саны өч кешедән дә ким була алмый.

## 5. Йомгаклау нигезләмәләре

5.1. Аттестацияләнүчегә карата документлар комплекты, тест нәтиҗәләре, рус телендә рәсмиләштерелә.

5.2. Аттестация узучыга аттестациянең һәр этабының уздыру датасы, урыны һәм вакыты турында электрон почта, гаризада күрсәтелгән контакт номерына шалтырату ярдәмендә аттестация этабын уздыруга кадәр җиде эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр ителә.

5.3. Аттесттацияләнүче аттестация комиссиясенең йомгаклау утырышында шәхсән үзе катнаша ала.

5.4. Аттестация комиссиясе тарафыннан Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2010 елның 26 августындагы 761н боерыгы белән расланган (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы тарафыннан 2010 елның 6 октябрендә теркәлгән, теркәү № 18638), Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2011 елның 31 маендагы 448н номерлы боерыгы белщнкертелгән үзгәрешләр белән (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы тарафыннан 2011 елның 1 июлендә теркәлгән, теркәү № 21240), «Мәгариф хезмәткәрләре вазыйфаларына квалификация характеристикалары» бүлегендә җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазыйфаларының Бердәм квалификация белешмәлегендә күрсәтелгән квалификация таләпләренә аттесттацияләнүченең хезмәт стажы һәм белеме өлешендә туры килмәве ачыкланганда, аттестация комиссиясе аттестацияләнүчене аттесттациянең алдагы этабын үткәнче аның квалификациясен һәм тәҗрибәсен эш бирүче тарафыннан тәкъдим ителгән язма раслауга нигезләнеп (аттестация узган вакытка аттестацияләнүченең эш урыны булмаган очракта, соңгы эш бирүче тарафыннан) аттестациягә кертү хокукына ия.

5.5. Аттестация комиссиясе карары белән аттестацияләнүче аттестация узмаган дип түбәндәгеләр шартларда танылa: педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнүгә чикләүләр булу, мәгариф өлкәсендә эшләү өчен чикләүләр булу, билгеләнгән һөнәри стандартларга һәм квалификация таләпләренә ачыкланган туры килмәү, ялган документлар куллану.

5.6. Тискәре карар алган һәм аттестацияне узмаган дип танылган аттестацияләнүчеләр аттестация комиссиясе тиешле карар кабул иткән вакыттан бер елдан да иртәрәк булмаган вакытта рөхсәт ителә.

5.7. Аттестация үткән аттестацияләнүчеләргә, аттестация комиссиясе тарафыннан аттестация узуны раслый торган, шул исәптән, тест үткәрү нәтиҗәләрен күрсәтеп, документ бирелә.

5.8 Җитәкче вазыйфасына кандидатны квалификация характеристикасында әлеге вазыйфа буенча билгеләнгән тиешле таләпләргә туры килми дип танылган очракта, аның белән хезмәт шартнамәсе төзелми.

5.9. Җитәкче аттестация комиссиясе карарын (рекомендацияләрен) үтәмәгәндә, билгеле бер белгечлекнең һөнәри әзерлеген уңышлы узуы яисә квалификация күтәрү өлешендә үтәмәгәндә, гамәлгә куючы хезмәткәргә карата Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 192 статьясы нигезендә дисциплинар җәза кулланырга хокуклы.

5.10. Җитәкчеләрне аттестацияләү мәсьәләләре буенча хезмәт бәхәсләре Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә карала.

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ нә ведомство буйсынуындагы мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы оешмалары җитәкчеләре (директорлары, мөдирләре) вазыйфаларына кандидатларны һәм җитәкчеләрен (директорларны, мөдирләрне) аттестацияләү тәртибенә 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы аттестация комиссиясенә
кемнән ____________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
___________________________вазыйфасына
(вазыйфа һәм учреждение исеме)
кандидат (яки вазыйфага билгеләнгән)
___________________________________________

ГАРИЗА

Мине 20____ елда
________________________________________________________________________
(вазыйфа һәм учреждение исеме)
вазыйфасы буенча квалификация характеристикасы таләпләргә туры килүне билгеләү (раслау) максатында аттестация үткәрүегезне сорыйм.
Үзем турында түбәндәге мәгълүматларны хәбәр итәм:
Туган ел, число, ай _______________________________________________________
Белеме (кайчан һәм нинди һөнәри белем бирү учреждениесен тәмамлаган, алган белгечлеге һәм квалификациясе)___________________________________________

________________________________________________________________________
Дәүләт яисә муниципаль идарә, менеджмент һәм икътисад өлкәсендәге юнәлешләр буенча өстәмә һөнәри белем (яисә квалификация күтәрү курслары)_________

________________________________________________________________________
Гомуми хезмәт стажы ___ _, шул исәптән педагогик эш стажы___________ , җитәкче эш стажы ______________ аттестацияләнә торган вазыйфада ____________ .
Бу учреждениедә эшлим (яки эшләмәдем) ____________ елдан.
Хезмәт кенәгәсеннән* (җитәкче вазыйфасына кандидатлар өчен) өземтә китерәм____________
Түбәндәге бүләкләргә, исемнәргә, гыйльми дәрәҗәгә, гыйльми исемгә иямен
________________________________________________________________________
ИКТ- технологияләргә ия булу дәрәҗәсе (югары, канәгатьләнерлек, түбән) (кирәклесен ассызыкларга)
Аттестацияне аттестация комиссиясе утырышында минем катнашымда (минем катнаштан башка) (кирәклесен ассызыкларга) үткәрүегезне сорыйм

Вазыйфа буенча квалификация характеристикасы таләпләре һәм «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУнә ведомство буйсынуындагы мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы белем бирү оешмалары җитәкчеләре вазыйфаларына кандидатларны һәм җитәкчеләрне аттестацияләү тәртибе белән таныштырылдым.

"_______"____________, 20 ел.     __________________     ________________

(Имза)     (ФИО)

Яшәү урыны адресы (факттагы) ________________________________

Контакт телефоны_________________________________________________

E-mail ______________________________________________________________

Хезмәт телефоны _______________________________________________________

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ нә ведомство буйсынуындагы мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы оешмалары җитәкчеләре (директорлары, мөдирләре) вазыйфаларына кандидатларны һәм җитәкчеләрен (директорларны, мөдирләрне) аттестацияләү тәртибенә 2 нче кушымта

КҮРСӘТМӘ

«__________» вазыйфасы буенча квалификация характеристикасында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау максаты белән аттестацияләнүче
_____________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
__________________________________________________________________
(билгән вазыйфасы, учреждение исеме)
(яки вазыйфага дәгъвачы _____________________________________________.
(вазыйфа, учреждение исеме)

1. Гомуми белешмәләр

Туу датасы ______________________________________________________________
(көн, ай, ел)
Белем турында белешмәләр _______________________________________________
(югары, урта һөнәри, башлангыч һөнәри, гомуми урта)
нинди белем бирү учреждениесен тәмамлаган_________________________________
______________________________________________ тәмамлау датасы: _________,
алган белгечлек: _____________________________________________________,
диплом буенча квалификация: _____________________________________________
«Дәүләт һәм муниципаль идарә», «Менеджмент», «Персонал белән идарә итү» юнәлешләре буенча белем _________________________________________________
Икенче белем булганда яисә алганда, нинди курста укуын күрсәтеп, белем бирүнең һәр юнәлеше буенча белешмәләр бирергә кирәк)
Идарә эшчәнлеге юнәлеше буенча квалификация күтәрү курслары (курсларның һәм өстәмә белем бирү учреждениесе исеме, тәмамлау елы, уку сәгатьләре саны) __
Гомуми хезмәт стажы ______ ел, шул исәптән педагогик эш стажы _________ ел,
җитәкче вазыйфаларда эш стажы __________ ел, шул исәптән мәгариф учреждениеләрендә ___________
Хезмәткәр аттестация узган вазыйфага билгеләнү датасы * ____________________
(әлеге пункт билгеләнгән җитәкчеләргә тутырыла)

П. Һөнәри эшчәнлектәге төп казанышлар

Педагогика вазыйфасы буенча квалификация категориясе барлыгы, бирелү елы _______________________________________________________________

Бүләкләре булу, бүләкләнү елы ________________________________________

Гыйльми дәрәҗәсе булу, бирелү елы ______________________________________

Башка һөнәри казанышлар __________________________________________________

III. Җитәкче вазыйфага билгеләнү өчен алшартлар

Мәгариф учреждениеләрендә җитәкче вазыйфалар биләүгә резервта _________________________________елдан торган
(резерв формалаштыручы мәгариф бүлеге исеме)

*Уңышлы эшчәнлекне күз алдында тоткан җитәкченең эшлекле һәм шәхси сыйфатлары булу* (эшлекле һәм шәхси сыйфатларның вазыйфасы буенча квалификация характеристикасында билгеләнгән таләпләргә туры килүе)___________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
Хезмәткәрнең мәгълүмати компетентлыгы (мәгълүмати, мультимедиа һәм цифрлы ресурсларга ия булу дәрәҗәсе)
Вазыйфасы буенча тест нәтиҗәләре, документны раслый торган документ_____
_________________________________________________________________________

Аттестация комиссиясе нәтиҗәләре һәм тәкъдимнәре:
_______________________________________________________________________________
_________________________________________________________________

Квалификация характеристикасында билгеләнгән таләпләргә туры килә (вазыйфасы күрсәтелә), һөнәри әзерлекне яисә квалификация күтәрүне уңышлы узган очракта (белгечлек күрсәтелә) квалификация характеристикасында билгеләнгән таләпләргә туры килә (вазыйфа күрсәтелә).

Һөнәри эшчәнлекне камилләштерү өчен тәкъдимнәр:

1.

2.

Мәгариф бүлеге башлыгы_________________ ( _________)
МУ
Күрсәтмә белән таныштырылдым______________ 20 __ ел
_____________________
(дата) (имз